Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Котлы Бөкәш
авыл җирлеге Советы

**КАРАР № I**

Котлы Бөкәш авылы 2019 елның 04 феврале

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге Советының 20 14 елның 13 октябрендәге "Җир салымы турында" XLV-I номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны гамәлдәге законнар белән тәңгәллеккә китерү максатларында, 2019 елның 29 сентябрендәге "Россия Федерацисе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында" 325-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге Советының "Җир салымы турында" карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге Советының 31 октябрендәге 2014 елның XLVI-II номерлы, 28 май 2015 елның LVIII-1 номерлы, 22 август 2017 елның XXXI-4 номерлы, 13 июнь 2019 елның V-2 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлештән гайре) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) (эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып

алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән гайре) җир кишәрлекләренә карата -0,3%”

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авылы, Совет урамы, 32йорт; Тәберде Чаллысы авылы, Совет урамы, 34 йорт; Мәмле Казаклар Чаллысы авылы, Үзәк урам 29 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Котлы Бөкәш авыл җирлеге
Башлыгы Г.Г. Нәҗипов